ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРМАЛКИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КАРМАЛКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

№2

2023 елның 30 октябре

Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлеге Мордва Кармалка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлеге Мордва Кармалка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 19 ноябренә 14 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Кармалка авыл җирлеге Мордва Кармалка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 85 яшьтән өлкәнрәкләр һәм махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

зиратны киңәйтү

Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- суүткәргечне ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мордва Кармалка авылы, Геодезия ур., 38 а йорт, 2 корылма (административ бина), Нагорный ур., 33 йорт (авыл мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка
авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы

О.В.Кириллова